БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» 06 2024 ел № 167

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 06 августындагы 235 номерлы карары белән расланган җир яисә муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән файдалану өчен җир кишәрлекләре тапшырмыйча һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2024 елның 13 мартындагы 02-07-2024/Прдп222 номерлы протестын карап, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 06 августындагы 235 номерлы карары белән расланган җир яисә муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән файдалану өчен җир кишәрлекләре тапшырмыйча һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүчегә карата Регламентта каралган нигезләмәләр мөрәҗәгать итүче вәкиленә кагыла.»;

1.2. 2.6.1 пунктында:

1, 2, 4 һәм 8 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.3. 2.8.2 пунктында:

6, 7, 9, 10,13 һәм 14 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт милке чикләнмәгән планлаштырыла торган җир кишәрлегенә карата объектларны урнаштыру өчен башкарма комитетка милекченең хокукларын гамәлгә ашыру хокукы бирелмәгән йә булган җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләре бирелмәгән;»;

түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча өстәргә:

15) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә дәүләт милкендә яисә муниципаль милектәге

җирдә яки җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкин булган объектлар исемлегенең 25 пунктында күрсәтелгән объектлар саныннан планлаштырыла торган урын велосипедлар, роликлар, самокатлар прокаты һәм башка спорт инвентаре пунктларын урнаштыру схемасында каралмаган, аларны урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми, шулай ук төрләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән объектларны урнаштыру шартлары һәм Тәртибенең 3 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән велопарковкаларны дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирдә яисә җир кишәрлекләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру өчен рөхсәт таләп ителми.»;

1.4. 3.6 бүлек:

түбәндәге эчтәлекле 3.6.1.1 пункт өстәргә:

«3.6.1.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә үзе сайлаган ысул нигезендә бирелә (җибәрелә).

Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасында язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны яисә тору урыны буенча почта аша (заказлы хат белән аларга тапшырылган документларны кушып) җибәрү; электрон почта адресы буенча һәм (яисә) Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә.

Мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮтә (МФЦ), КФҮнең эш регламенты нигезендә, Балтач муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан җибәрелгән, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документның кәгазьдә басылган нөсхәсе рәвешендә алырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.6.2.3 пункт өстәргә:

«3.6.2.3. Мөрәҗәгать итүче, аның вәкиле Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән килгәндә, документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели, шул исәптән шәхесен раслаучы документны тикшерә;

вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирә һәм документлар бирү турында исәпкә алу кенәгәсендә язып куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе.».

1.5. 5.2 пунктында:

«муниципаль хезмәт күрсәтүче, тапшырылалар» сүзләреннән соң «ведомствоара комиссиягә,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Галимуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов